## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең Арбор авылы торак пунктында

«06» ноябрь , 2026 ел.

№2

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең Арбор торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең Арбор авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 13.01.2025 ел, № 14 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1, һәм 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең Арбор авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, тулы булмаган гаиләләрдән тыш, 2026 елда үзара салым акчасын 950 сум күләмендә кертергә.балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия Федерациясе Кораллы көчләрендәге контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: -юл-урам челтәрен һәм асфальт-бетон өслекне норматив хәлгә китерү; торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: - Арбор авылында балалар мәйданчыгын төзекләндерү.»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Чепья авыл җирлеге башлыгы

А.Г. Нотфуллин